**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 169-19 «12» октябрь 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2018 елның 19 апрелендәге 188-28 номерлы «Бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре таралмаган, бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» (23.05.2019 №259-36, 20.08.2019 №280-38, 24.08.2020 №366-48, 25.02.2022 №113-15 карарлар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 02 августындагы 751 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы 195 нче номерлы "Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган аерым оешмаларда эшләүчеләрнең хезмәт хакы шартлары турында" карарына үзгәрешләр үзгәрешләре кертү хакында», 2022 елның 22 августындагы 878 номерлы «Бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәт хакын түләү буенча бердәм тариф челтәре таратылмый торган аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында» карарлары нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар итә:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2018 елның 19 апрелендәге 188-28 номерлы «Бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре таралмаган, бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» (23.05.2019 №259-36, 20.08.2019 №280-38, 24.08.2020 №366-48, 25.02.2022 №113-15 карарлар редакциясендә) карарында күрсәтелгән тәртиптә бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре таралмаган бюджет өлкәсендәге аерым оешмаларның җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмен 2022 елның 01 октябреннән арттырырга.

2. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2018 елның 19 апрелендәге 188-28 номерлы «Бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре таралмаган, бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» (23.05.2019 №259-36, 20.08.2019 №280-38, 24.08.2020 №366-48, 25.02.2022 №113-15 карарлар редакциясендә) карары белән расланган, бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре таралмаган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 1.4 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларының күләмнәре муниципаль берәмлекләрдә аерым бюджет өлкәсе оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесенең вазыйфаи оклады буенча исәпләнә, ул 11 958,0 сум тәшкил итә.».

2.2. 2.4 пунктның 2, 3 абзацларын төшереп калдырырга;

2.3. 3.2 пунктның 7 пунктчасының өченче абзацында «7 процент тариф ставкасы» сүзләрен «хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. түбәндәгеләрне билгеләргә:

- әлеге карарның 2.1 пунктының гамәлдә булуы 2022 елның 01 октябреннән үз көченә керә;

- әлеге карарның 2.2., 2.3 пунктларының гамәлдә булуы 2022 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин